КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 3 ноябрь г.Казань № б-2217

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең дәүләт бүләк бирү системасын камилләштерү буенча чаралар турында» 2010 елның 7 сентябрендәге 1099 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре турындагы нигезләмә нигезендә:

1. Даими саклау һәм экспозиция-күргәзмә эшчәнлегендә файдалану өчен Татарстан АССРның түбәндәге дәүләт бүләкләрен һәм аларга теркәлә торган документларны «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесенә тапшырырга:

1946 елгы 625 номерлы Ленин орденын;

1970 елгы 036 номерлы Октябрь Революциясе орденын;

1972 елгы 026 номерлы Халыклар дуслыгы орденын;

285303 номерлы Ленин орденына орден кенәгәсен;

16284 номерлы Октябрь Революциясе орденына орден кенәгәсен;

017723 номерлы Халыклар дуслыгы орденына орден кенәгәсен.

2. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин